ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә мәҗбүри яклары булып бер үк вакытта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы булган махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы күләмен билгели.
2. Әлеге Закон максатларында махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар булып Россия Федерациясе Салым кодексының $25^{16}$ статьясы нигезендә махсус инвестиция контрактларында катнашучы салым түләүче затлар танылa.»;

2) 2 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы 13,5 процент күләмендә билгеләнә.»;
б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Махсус инвестиция контрактларында катнашучы йөк автомобиль транспорты чараларын җитештерүче оешмалар өчен Татарстан Республикасы

бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы 2025 елга кадәр (бу елны кертеп) 0 процент күләмендә билгеләнә.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән оешмалар табышына салым буенча салым ставкалары махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының $284^{9}$ статьясында каралган тәртиптә кулланыла.»;

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Махсус инвестиция контрактларында катнашучыларга киметелгән салым ставкаларын куллану өчен Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән шартлар әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар тарафыннан үтәлмәгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалар өчен махсус инвестиция контракты төзелгән салым чорыннан алып үзенә карата махсус инвестиция контракты төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында җитештерелгән товарларны сатудан салым исәбе белешмәләре буенча беренче табыш алынган салым чорына кадәр, әмма махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соңрак булмаган һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңрак булмаган вакытта, 13,5 процент күләмендә кулланыла.»;

3) 3 статьяда:

а) «Әлеге Закон» сүзләрен «1. Әлеге Закон» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлектәге 2 өлеш өстәргә:

«2. Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән махсус инвестиция контрактларында катнашучы салым түләүчеләргә карата кулланыла.».

**2 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш) гамәлдә булуын туктатырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән бер ай үткәч, әмма оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 28 ноябрь
№ 89-ТРЗ